**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Рангазарского сельского**
**поселения Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы**
**Рангазар авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 12** **“ 18 ” 09 2024 ел**

**Ветераннар һәм инвалидларның иҗтимагый оешмалары чыгымнарын өлешчә каплауга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга күрсәтелгән субсидия, эшләр, хезмәт күрсәтүләр алучыларга, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары нигезендә Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән ветераннарның һәм инвалидларның иҗтимагый оешмалары чыгымнарын өлешчә каплауга субсидияләр бирү тәртибен (1 нче кушымта) расларга.

2. Әлеге карар имза салынган вакыттан үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә булган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рангазар авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Н.Кыямов